**Г.М.Сунгатов**
*Республиканский центр развития традиционной культуры*

# Телнең төрле стильләрендә әйберләр күләмен һәм зурлыгын белдерүче үлчәм берәмлекләренең кулланылышы

*фольклор, әдәби әсәрләр теле, метрологик лексика*

Әйберләрнең күләмен һәм зурлыгын, азлыгын-күплеген, авырлыгын белдерүче тел берәмлекләре татар теленең сүзлек составындагы иң борынгы лексик-семантик төркемнәргә карый. Элекке үлчәм берәмлекләренең күбесе телнең төрле тармакларында хәзер дә актив кулланылалар. Әлеге мәкаләдә татар халык авыз иҗатында, әдәби әсәрләрдә һәм матбугат телендә әйберләр күләмен һәм зурлыгын чагылдырган тел чараларын, башлыча үлчәм берәмлекләрен тикшерү максат итеп куела. Билгеле булганча, халык авыз иҗаты әсәрләрендә кешеләрнең бик борынгы чорлардан алып яшәү, тормыш итү рәвеше чагылыш таба. Шунлыктан фольклор текстларында борынгыдан килгән үлчәм берәмлекләренең еш кулланылуы бик табигый. Матур әдәбият әсәрләрендә һәм төрле стильләр чагылыш тапкан матбугат телендә, лексиканың башка тармаклары кебек үк, метрологик лексика да яңа сүзләр белән байый, алынмалар хисабына тулылана бара.

Күләм – нәрсәнең дә булса озынлык, биеклек һәм киңлек ягыннан күп берәмлекләр белән үлчәнә торган зурлыгы [Татар 1979, 2: 296]. Ул киң кулланылышка ия булган, тормышның төрле тармакларында чагылыш таба торган үлчәм берәмлекләренең берсе. Күләм билгесе төрле тармактагы әйберләрнең – каты, сибелүчән һәм вак бөртекле предметларның, сыек җисемнәрнең барысына да, газсыман матдәләргә дә, абстракт мәгънәле әйберләр һәм төшенчәләргә дә хас. Күләм мәгънәләре башлыча телдә зур бер тармакны тәшкил итә торган нумератив сүзләр белән тәгъбир ителәләр. Тел белемендә нумератив сүзләр дип аергыч ролендә килгән саннарга иярә торган махсус ачыклагыч сүзләргә әйтәләр. “Алар гадәттә аергыч белән аерылмыш (сан белән исем) арасында әйтеләләр. Бу сүзләр саналмыш предметның сыйфаты белән ярашкан булалар һәм нәтиҗәдә алар телдә аерым категория сүзләргә генә хас хас булган нумератив билге булып урнашканнар” [Татар 2002, 2: 88].

Үлчәм берәмлекләре, халыкның яшәеше, тормыш итүе белән турыдан туры бәйләнешле булганга, телнең актив кулланылышлы лексикасына керәләр, ягъни барлык тармакларда да кулланылалар. Әйтик, халыкның күпьеллык тәҗрибә-күзәтүләрен чагылдырган мәкаль-әйтемнәрнең шактый өлешендә күләм төшенчәсен чагылдырган лексика урын ала. Мәсәлән, “Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр”

җыентыгында түбәндәге мәкаль-әйтемнәр урын алган: ***бер тамчыдан диңгез булмый; бер кашык су белән йотарлык; диңгездән бер тамчы; Идел суы илле батман; артыңнан бер чиләк ком; төн карыны бер колач; учлап чәчсәң, йөкләп җыярсың; бер корт анасын тоткан бөтен күчен тотар*** һ.б. [Татар халык 1987 ]**.**

Әйберләрнең зурлыгы-кечкенәлеге, агачларның юанлыгы, хайваннарның гәүдә зурлыгы һәм тазалыгы әкият текстларында туры мәгънәсендәге гади сыйфатлар белән белдерелә ала. Мәсәлән: ***калын агач*** [“Наян Төлке”]; *ясаткан бу **бик олы итеп абзар*** [“Абзар ясаучы Төлке”]; ...***атлар бик зур, арбалар бик авыр*** [“Салам-Торхан”], ***кечкенә сандык*** [“Каракош”]; *өч байтал икән. Өчесе дә **тау хәтлеләр, зурлар*** [“Ак байтал”] һ.б. Әкиятләрдә предметның зурлыгы башка бер әйбернең зурлыгы белән чагыштырылып күрсәтелергә мөмкин. Мәсәлән: “***кеше башы хәтле алма** алып кайт”, – ди* [“Өч бүләк”].

Тупланган материаллардан күренгәнчә, татар теленең төрле стильләрендә предметларның күләмен белдерә торган нумератив сүзләр арасында ***уч**, **йөк**, **төенчек**, **шакмак**, **түтәрәм**, **түшкә**, **бөртек, олау, кап*** кебек борынгыдан килгән татар сүзләре еш очрый, матур әдәбиятта һәм матбугат телендә ***процент**, **порция, литр, рюмка*** кебек алынма сүзләр дә кулланыла. Кечкенә күләмле сибелүчән предметлар ***чеметем*** нумератив сүзеннән башлап белдерелсә, зур күләмле әйберләр әдәби әсәрләр телендә **йөк**, **олау** кебек исемнәр аша аңлатыла. Кайбер мисаллар: ***бер чеметем тоз*** [В.Т., 15 июл. 2016]; ***1 чеметем тоз*** [С.С., нояб. 2016]; **кырык олау арслан-киек сөяге** [“Аучы егет”]; ***бер бик олы кап белән мал*** [“Убыр-Таз”]; ***бер олау кызыл балчык*** [Мәһдиев, “Каз канатлары”]; ***дүрт йөк бодай*** [Гыйләҗев “Дүртәү”]; ***бер янчык чикләвек*** [Нуруллин “Күпер чыкканда”]; ***бер кап шырпы*** [Гыйләҗев “Җомга көн кич белән”]; ***1 кап солы лачаулары*** [Ю-ш, 14 гыйн. 2017] һ.б. ***Машина*** сүзенең нумератив ролендә килүе исә – 20 гасыр урталарында гына туган күренеш: *әнә шул **бер машина онны** Шәйхиегез кичә калага илттереп саттырды* [Нуруллин “Аккан су юлын табар”].

Печән, салам, үлән кебек предметларны атаучы сүзләр, күпмедер үсемлекнең тупланмасын белдереп, метрологик лексика составында аерым төркем тәшкил итәләр. Төрле үсемлекләрнең күләме гадәттә ***кочак**, **уч**, **учма**, **арба**, **олау*** кебек нумератив сүзләр ярдәмендә аңлатыла. Кайбер мисаллар: ***чүмәлә кадәр печән*** [Мәһдиев “Кеше китә – җыры кала”]***; учма-учма үлән***; ***учмалап-учмалап үлән*** [Хәлим “Исемсез малай”] һ.б. Без күзәткән әсәрләр телендә утынның күплеге һәм күләме гадәттә сан белән ачыкланып килгән яки саннан башка гына кулланылган нумератив сүз белән күрсәтелә: ***ике йөк каен утыны*** [Мәһдиев “Кеше китә – җыры кала”]; ***бер кубометр утын*** [Нуруллин “Әгәр син булмасаң”] һ.б. Әдәби әсәрләр телендә **кышлык утын** сүзтезмәсе еш очрый, бу очракларда ул бер йортка кыш буе ягып

чыгарга җитәрлек утын күләмен аңлата. Мәсәлән: *кем **кышлык утын** хәзерләшер соң инде миңа* [Нуруллин, "Әгәр син булмасаң"].

Күләм төшенчәсенә мөнәсәбәтле берәмлекләр арасында кайсы да булса бер әйбернең өлешен яки кисәген белдерә торганнары бар. Болар – ***кисәк**, **сынык**, **процент**, **түтәрәм*** кебек сүзләр. Әкиятләрдән мисаллар: ***бер кисәк икмәк*** ["Аучы егет"]; ***бер генә сынык ипие*** ["Хәйләкәр патша"]; ***бер кисәк алтын*** ["Дутан батыр"]; ***30 процент*** [Т.Я., 29 окт. 2015]; ***2 % бакыр хлорокисе*** [Ю-ш, 19 дек. 2015]; ***бер түтәрәм майны*** [Мәһдиев "Каз канатлары"]; ***зур гына түтәрәм каз ите*** [Гыйләҗев "Дүртәү"] һ.б. Борынгыдан килгән ***түтәрәм*** сүзе "дүрттән бер өлеш, чирек; 2 бер кадак (400 грамм) чамасы; зур кисәк (ит, икмәк һ.б.ш. турында)" мәгънәләрен белдерә [Татар теленең 1981, 3: 290].

Әкиятләрдә дә, әдәби әсәрләр һәм матбугат телендә дә каты яки сыек әйберләрне белдерү өчен дә, вак бөртекле һәм сибелүчән предметларның күләмен чагылдыру өчен дә нумератив сүзләр буларак савыт-саба атамалары, зуррак күләмле әйберләрне белдерү өчен **мичкә**, **кисмәк** кебек сүзләр еш кулланыла. Әкиятләрдән мисаллар: ***бер табак токмач*** ["Фикерле кыз"]; ***бер тәпән баллары, бер тәпән сары майлары*** ["Аю белән Төлке"]; ***кырык мичкә дегет*** ["Ак байтал"]; ***бер рюмка аракы*** ["Аучы егет"]; ***ике шешә эчемлек*** ["Дутан батыр"]; ***кырык мичкә спирт*** ["Аучы егет"]: ***бер чүмеч аракы*** ["Алдакчы Тимер"]; ***бер чиләк кан*** ["Алдакчы Тимер"]; ***бер чиләк су*** ["Аучы егет"] һ.б. Әгәр алдагы җөмләләрдән аңлашылса, нумератив сүз ачыклый торган җисемнең исеме яңадан әйтелмәскә дә мөмкин. Мәсәлән: ***ике чынаякны** эчеп* бетерә ["Аңгыралык бәласе"]. Әдәби әсәрләрдән мисаллар: ***ярты чиләк бәрәңге; бер чокыр тәмәке суы*** [Мәһдиев "Кеше китә – җыры кала"]; ***ярты тәлинкә аш*** ["Каз канатлары"]; ***мичкә-мичкә терек суы*** [Гыйләҗев "Өч аршын җир"] һ.б. Хәзерге татар матбугатында савыт-саба атамалары су, бал, төнәтмә кебек сыек җисемнәр күләмен белдерү өчен төрле файдалы киңәшләр бирелгән рубрикаларда бик актив файдаланыла. Мәсәлән: ***2 стакан шифалы су, 2 аш кашыгы бөтнек сиробы, бер чиләк су*** [В.Т., 15 июль 2016]; ***3 ыстакан су**; **2 ашкашык катнашма*** [Ю-ш, дек. 2015]; ***ярты стакан яңа сыгылган миләш согы*** [М.Җ., 30 дек. 2016]; ***ике аш кашыгы* бал** [С.С. нояб. 2016]; ***200 мең стакан сөт*** [Акч-к, 17 дек. 2015]; *4-10 кашык бал* [Ак-к, 3 нояб., 2016]; ***2 чынаяк кураҗиләк яфраклары төнәтмәсе*** [Ю-ш, дек. 2015] һ.б.

Фольклор әсәрләреннән аермалы буларак, әдәби әсәрләр һәм матбугат телендә сыек җисемнәрнң күләмен белдергәндә **литр**, **миллилитр** кебек алынма сүзләр актив кулланыла. Мәсәлән: ***чирек литр керосин*** [Мәһдиев "Без – кырык беренче ел балалары"]; ***егермешәр литр сөт*** [Нуруллин "Әгәр син булмасаң"]; ***70 мл су; 50 мл шулпа*** [В.Т., 18 нояб. 2016]; ***500 мл ит шулпасы, 2 литр су*** [ С.С., окт. 2015]*; **2 литр эремчек суы**, **1,5 л су**, **1 л куе йогырт**, **1 л шифалы су***

[В.Т., 15 июль 2016]; ***1 литр катнашма*** [М.Җ., 30 дек. 2016]; ***1 л җылы су*** [Ю-ш, дек. 2015] һ.б. Күргәнебезчә, сыеклык үлчәме берәмлекләре вариантлы язылыш хасил итәләр – алар кыскартылма сүз буларак биреләләр. Мондый очракларны бертөрлелектән арыну җәһәтеннән дә, орфографиянең экономия принцибын гамәлгә ашыру ягыннан да табигый һәм урынлы күренеш дип бәяләргә кирәк.

Фольклор әсәрләреннән аермалы буларак, матур әдәбият һәм матбугат телендә газсыман матдәләрне, радиация һәм һава күләмен атаучы күрсәткечләр дә кулланыла. Кайбер мисаллар: ***миллионлаган кюри атом калдыклары*** *тарала; төннәрендә* ***йөз ун сантизиверт радицаия*** *йөрткән кешеләр* [Бәйрәмова “Караболак”]; *бер сыер көнгә* ***400 литр метан газы*** *(иң агулы газларның берсе) бүлеп чыгара* [ТЯ, 22 окт. 2015].

Йомгаклап әйткәндә, фольклор, матур әдәбият әсәрләрендә һәм матбугат телендә каты предметларның, сибелүчән, вак бөртекле әйберләрнең, сыек җисемнәрнең һәм газсыман матдәләрнең күләмен белдерү өчен бай лексик материал файдаланыла. Алар арасында төп урынны татар теленең борынгыдан килгән үз сүзләре алып тора. Күләмне белдерүче нумератив сүзләр арасында тамыр исемнәр дә (***уч***, ***кап***, ***йөк***, ***бура*** һ.б.), ясагыч кушымча ярдәмендә ясалганнары да бар (***телем***, ***кыерчык***, ***учма***, ***төргәк*** һ.б.). Матур әдәбият әсәрләрендә һәм матбугаттагы язмаларда совет чорында үтеп кергән кайбер рус-европа алынмалары да нумератив функциясендә урын алганнар. Болар – ***порция***, ***процент, посылка, машина, кубометр*****,** һ.б. шундый сүзләр. Газета битләрендә бер төркем сүзләрнең вариантлы язылышы һәм кулланылышы күзәтелде: ***чәй кашыгы – балкашык; аш кашыгы – ашкашык; стакан – ыстакан; процент –*** *%;* ***литр – л; миллилитр – мл*** һ.б.

Әйтелгәннәрдән чыгып, әлеге мәкаләдә күзәтелгән тел стильләрендә күләм мәгънәсен белдергән нумератив сүзләр белән күбрәк тормыш-көнкүрешкә караган әйберләр, ашлык, яшелчә, җиләк-җимеш, азык-төлек атамалары ачыкланып килә, чәй һәм су күләмнәре белдерелә, һава күләмен белдерүче берәмлекләр азрак очрый дигән нәтиҗәгә киләбез.

**Әдәбият**


Татар грамматикасы. Мәскәү – Казан: Инсан. Фикер, 1998. Т. 1. – 512 б.; 2002. Т. 2. – 448 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. Т. 1. – 476 б.; 1979. Т. 2. – 726 б.; 1981. Т. 3. – 832 б.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр, 1 кит. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1977. –408 б.; 2 кит. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1978. – 448 б.; 3 кит. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1981. – 360 б.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. – 591 б.